ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

2020 елның 29 июленнән №180

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлегенең
«Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге территорияләрен
төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»
2019 елның 14 февралендәге
128 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендә кабул ителгән 128 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, тиешле тәртиптә тоту, җыештыру, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү, тиешле тәртиптә тоту, җыештыру, чистарту һәм тәртипкә китерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 10 бүлекне түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«10.2 Җир кишәрлекләрен Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар.

10.2.1 Җир кишәрлекләренә хокукчылар үзләренең милкендәге, биләгән яисә файдаланган җир кишәрлекләрен Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар үткәрергә тиеш.

10.2.2 Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар аның чәчәккә бөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.

10.2.3 Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар түбәндәге ысуллар белән үткәрелергә тиеш:

химик - гербицидлар һәм (яисә) арборицидлар белән үсеш учакларын сиптерү;

механик - чабу, коры үсемлекләрне урып-җыю, тамырларын алып ату;

агротехник - туфрак эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.»

2. Әлеге карарны Татар Чаллысы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгы Кузнецовка Т.П. йөкләргә.

Татар Чаллысы
авыл җирлеге Башлыгы Т.П.Кузнецова